**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.05.2019 пгт. Рыбная Слобода № 180пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 февралендәге 63пи номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урман кишәрлекләре (массивлары) белән чиктәш гражданнарның торак пунктлары, балалар сәламәтләндерү оешмалары, бакчачылык, һәм коммерцияле булмаган дача берләшмәләре территорияләрендә янгынга каршы махсус режим билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, «2019 елда Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар турында» 1999 елның 13 мартындагы 180 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 февралендәге 63пи номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урман кишәрлекләре (массивлары) белән чиктәш гражданнарның торак пунктлары, балалар сәламәтләндерү оешмалары, бакчачылык, һәм коммерцияле булмаган дача берләшмәләре территорияләрендә янгынга каршы махсус режим билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 1 нче кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Янгынга каршы режим - янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, корылмаларны, оешмалар биналарын һәм башка саклау объектларын җитештерү һәм (яки) карап тотуны оештыру тәртибен билгели торган янгын куркынычсызлыгы таләпләренең Россия Федерациясе норматив хокукый

актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән янгын куркынычсызлыгы таләпләре җыелмасы»;

1.2) 1 нче кушымтаның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Янгын куркынычы арткан очракта, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисе үз карары белән торак пунктларда, балалар сәламәтләндерү оешмаларында һәм урман кишәрлекләре (массивлары) белән чикләнә торган бакчачылык, яшелчәчелек, коммерцияле булмаган дача берләшмәләрендә билгели. Аерым янгынга каршы режимны билгеләү турында карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 13.03.2009 ел, №180 карары белән расланган «2019 елда Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар турында» исемлеге нигезендә, торак пунктларда яшәүчеләр, балалар сәламәтләндерү оешмалары, бакчачылык, яшелчәчелек, һәм коммерцияле булмаган дача берләшмәләре тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри булып тора.

2. Әлеге карарны Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru һәм» Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында " Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Д. Н.Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов